وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№9 (106). 14 октябрь 2011 / 17-зөлкагъдә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Метеор кебек ялтырады" ▷2◁



Дин һәм милләт – кешенең ике канаты ул ▷3◁



Хикмәтле төш ▷4◁

### ДОНОР КАНЫ ТАПШЫРЫЛДЫ

6 октябрьдә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре һәм Мөселман яшьләре берләшмәсе вәкилләре Республика клиник хастаханәсенең кан тапшыру үзәгендә кан бирде. Мондый чараның максаты – донор канына булган ихтыяҗны каплау. Киләчәктә дә мондый төрдәге акцияләр дәвам итәр, дип көтелә.

### АБЫСТАЙЛАР ҖЫЕЛДЫ

Узган җомгада "Мәрҗани" мәчетенең актлар залында "Гасыр абыстайлары" дип исемләнгән чара үтте. Әлеге чарада республикабызда ислам динен саклап калуга һәм үстерүгә, әдәп-әхлак каннуннарын таратуга, динебез үсешенә үзләреннән бәяләп бетергесез өлеш керткән абыстайлар катнашты. Абыстайларны "Мөслимә" дип исемләнгән иҗтимагый оешма җитәкчесе Әлмирә Әдиятуллина җыйган иде.

"Гасыр абыстайлары"н котлау өчен ТР Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе хезмәткәре Чулпан Мәхмүтова, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең беркетмәләр бүлеге мөдире Илшат Насыйбуллин, мөфтиятнең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге мөдире Гөлнара Садыйкова, Республика клиник тире-венерология диспансерының физиотерапевтика бүлеге мөдире Миләүшә Гайфуллина, Иран ислам республикасының Татарстандагы консуллыгы вәкиле – мәдәният буенча атташе Гасеми Парвез, Бөтендөнья татар конгрессы әгъзалары һ.б. килгән иде. Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән И.Насыйбуллин динебез, милләтебез юлында куйган хезмәтләре өчен олы рәхмәтен җиткереп, истәлекле бүләкләр тапшырды.

### КАЗЫЙЛАР ШУРАСЫ ҮТТЕ

10 октябрь көнне мөфтият бинасында Казыйлар шурасы утырышы булып узды. Утырышта төньяк казыятнең алты казые (Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Теләче) районнардагы эшчәнлекләре буенча исәп-хисап тотты. Имам-хатыйблар шулай ук якынлашып килүче Корбан бәйрәменә кагылышлы кайбер сораулар буенча да фикер алышты.

### ХАҖИЛАР ЮЛГА ЧЫКТЫ

12 октябрь иртәсендә "Казан" халыкара аэропортыннан 98 кеше хаҗга юл тотты. Быелның беренче хаҗилар төркеме маршруты түбәндәгечә төзелгән: Казан – Истанбул – Мәдинә – Мәккә – Җиддә – Истанбул – Казан. Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз хаҗиларга хәерле сәфәрләр теләп, аларны олуг сәфәргә озатты.

***DUMRT.RU***

# РУХИ ДӨНЬЯ

**Без еш кына кешенең рухи асылы, мөселман өммәтенең үсешенә бәйле әһәмиятле мәсьәләләр турында (күп очракта моның бөтен мәгънәсен аңлап бетермәстән) сүз куертырга яратабыз. Нәрсә соң ул адәм баласының рухи дөньясы? Аңлатмалы сүзлекләрдә әлеге сүзнең мәгънәсенә дин белән бәйләп аңлатма бирелә. Үзләренең шул рухи башлангычларына төшенүләрен аңлап та бетермәгән кайбер атеистлар да рухилык булу-булмау турында бәхәсләшә. Рухилык - ул кешенең асылы, ул аның башлангычы белән бәйле. Кеше үзенең рухи асылын тойганда гына чып-чынлап яши, үсешкә омтыла ала.**

**Хәзер, кызганыч ки, безнең омтылышларыбызны һәм илебезне үстерү юлларын билгеләү өчен кеше психикасының эчке резервларын кулланып, җәмгыятебез массакүләм мәгълүмат чаралары аша кешелекнең традицион рухи байлыкларына каршы килгән кыйммәтләр системасы булдырды. Шуңа күрә беренче урынга гаделлек һәм илтифатлылык кына түгел, ә кешеләр тарафыннан дөнья ләззәтен тою алгы планга чыга. Һәрхәлдә, мондый уңышларга ирешкән кеше тышкы яктан үз дөньясының хуҗасы кебек кабул ителә башлый (бу җәмгыять үсеше өчен яхшы сыман), әмма кешенең эчке дуамаллыгы аның тышкы дөньясын саектыра, шул сәбәпле җан дәвасын таба алмый ул. Ник дигәндә, ныклы җәмгыять үсешенә рухи сыйфатлар да йогынты ясый. Моның өчен безгә рухи мирасыбызга да мөрәҗәгать итү таләп ителә әле.**

**Бүгенге көндә кылган гамәлләребез, яшәешебез киләчәгебезнең нигезен, кыйбласын билгели. Киләчәктә җәмгыятебез көчле һәм барлык халыкларга, милләтләргә карата дуслык-татулык сыйфатларын үткәрүче булу-булмавы да нәкъ менә үзебезгә бәйле.**

**Без барыбыз да фитри иман белән дөньяга киләбез. Шуңа да бүгенге көндәге югары әһәмияткә ия булган кыйммәтләр, ягъни кешелеклелек кыйммәтләре, чынлыкта исә ислам диненең асылын, нигезен тәшкил итәләр. Дин йогынтысына ят булган, дин белән, гомумән, кисешмәгән, дини яктан бәя бирелми калган эш-гамәл, мөнәсәбәт, өлкә була алмый.**

**Ышанып әйтә алам: рухи мирасыбызга, халкыбызның матур традицияләренә әйләнеп кайту, аларны өйрәнү, үзебезнең тормышыбызда, яшәү рәвешебездә кыйбла итеп алу - җәмгыятебезне рухи һәм әхлакый яктан үстерәчәк кенә. Тарихыбыз шактый катлаулы, тирән һәм кызыклы. Әби-бабаларыбыз тарафыннан йөзләрчә еллар буена тупланган рухи һәм мәдәни ядкарьләребез - менә кайда ул чын хакыйкый байлык! Бары тик шушы кыйммәтләр белән генә якты, матур киләчәк төзеп була, шулар аша гына җәмгыятебездә иминлек урнаша ала.**

**Киләчәктә динебезгә, милләтебезгә хезмәт итәрлек ватанпәрвәрләрне, югары әхлакка ия булган чын инсани затларны гасырлар буена тупланып килгән шушы кыйммәтләр нигезендә генә тәрбияләп була. Рухи-әхлакый кыйммәтләр җәмгыятебездәге мәгариф сәясәтенең дә төп сыйфаты булырга тиеш. Бу өлкәдә дәүләт, җәмгыять һәм мөселман өммәте бердәм хезмәттәшлек күрсәтсә, киләчәгебез өчен дә хафаланыр урыннар калмас иде.**

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***



www.painterliya.com/suumbike.htm

*Сөембикә манарасы*

# Сөембикәнең серләре күп

**Казан ханлыгы өчен көчле сугышлар 458 ел элек - 1552 елның август айларында ук башлана. 12 октябрь көнне мәркәзебезне саклаучы татарлар руслар тарафыннан тар-мар ителә, дәүләтебез басып алына. Нәкъ шушы көннәрдә Казан дәүләте Мәскәү кулына төшә, сугышта исән калучыларны кырып бетерәләр, шәһәр талана, яндырыла, җимерелә, дәүләт символлары Россия башкаласына озатыла. Казаннан соң Нугай Урдасы, Кырым, Әстерхан, Себер ханлыклары юк ителә...**

Казан ханлыгының яулап алынуы Сөембикә трагедиясе белән бәйле. Улы белән Мәскәүгә әсирлеккә озатылган ханбикәнең каргышы була, күрәсең, татарлар аны русларга тапшырып, оборонага әзерләнеп өлгерербез, дип уйлый, ләкин эшләре барыбер уңмый. Кем гаепле? Сөембикәне Мәскәүгә сатмасалар, дәүләтне саклап калып булыр идеме? Бу сорауларны тарихчы Марсель абый ӘХМӘТҖАНОВ белән ачыкларга тырыштык.

**- Марсель абый, Сөембикәнең тормыш юлы нинди? Аның улы гына түгел, кызы да була, диләр.**

- Сөембикә - татар тарихында билгеле зур шәхесләрнең берсе. Ул якынча 1518-1519 нчы елларда Нугай Урдасының Йосыф морза гаиләсендә дөньяга килә. Алар турыдан-туры Идегәйнең токымына бәйле. Кардәшлекләре Кырым, Себер ханлыкларына, Урта Азия дәүләтләренә барып тоташа.

1533 елда Мәскәү гаскәр җибәреп Казанны басып ала. Дәүләт белән хакимлек иткән Сафагәрәйгә чыгып китәргә туры килә. Казан тәхетенә Касыймнан Җангалине китертеп утырталар. Ул - Шаһгалинең бертуган энесе. Менә шул Җангалигә Йосыф морзаның иң матур һәм зирәк кызы Сөембикәне хатынлыкка бирәләр. Сафагәрәй дә тик ятмый, тәхетен кире кайтарырга тели. 1535 елда абыйсы Сәхипгәрәй ярдәме белән Казанга кире кайта һәм хакимлек итә башлый. Бу гамәле белән ул Мәскәүгә берникадәр дәрес бирә. Җангалине Казанда яратмыйлар, бәрелешләр булган вакытта ул үтерелә. Сөембикә Сафагәрәйгә ошаган, күрәсең, шулай ук дипломатияне күз алдында тотып, Нугай Урдасы ханәкәсе Сөембикәне кыерсытмый, үзенә хатынлыкка ала. Аның башка хатыннары да була. Ләкин Сөембикәне ныграк ярата, диләр. Сөембикә тол калганда йөкле була. Аның Җангалидән кызы туа. Бу кыз баланың исеме мәгълүм түгел, ләкин аның тормыш юлы кызыклы. Сөембикәнең кызы бераз үскәч, Касыйм ханы Шаһгали аны кызлыкка бирүен үтенә, чөнки үзенең балалары булмый. Энесенең баласы бит, кыз Касыймга китә. Беркадәр вакыт узгач, 1552 елда Кырым ханы Аккүбәкнең улы Кайбула ханлыктан куып чыгарыла, ул Нугай Урдасына килеп эләгә һәм Мәскәү яклылар аны руслар файдасына эшләргә кодалый башлый. Кайбула Мәскәүгә килә һәм аны Шаһгали карамагында үскән Сөембикәнең кызына өйләндерәләр. Аларның бишләп баласы туа. Аны тагын ике бояр кызына өйләндерәләр, ләкин алардан балалары булмый. Ике хатыны да 1605-1610 елларда монастырьдә монахинялар булып үлә. Күрәсең, Кайбула чукынмаган. Ул 1570 елда ук вафат була.

**(Ахыры 3 нче биттә.)**

## ИГЪЛАН

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды якынлашып килүче Корбан бәйрәме уңаеннан корбан чалуга гаризалар кабул итә. Корбан ите мохтаҗ гаиләләргә, ятим-мескеннәргә таратылачак.**

**Исегезгә төшереп үтәбез: быел Корбан гаете 6 ноябрьдә билгеләп үтеләчәк.**

**Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә:**

***420111 ТР, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.***

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН:

**+7 (843) 236-46-32, 264-60-08;**

**факс: 236-37-62.**

**Сайт: www.закят.рф.**

**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**

Благотворительный Фонд Закят

# Татар халкының милли спорт төре Олимпиада программасына кертелергә мөмкин

**Универсиададан соң билбау көрәше Олимпия уен төре булырга мөмкин.**

Төрки халыкларда традицион уен төре булган билбау көрәше (көрәш) Олимпиада программасына эләгергә мөмкин. "Моңа 2013 елда Казанда узачак XXVII Дөньякүләм җәйге Универсиада этәргеч бирергә тиеш", - дип белдерде әлеге спорт төренең Халыкара федерация президенты Людмила Гайнанова.

Билбау көрәше буенча дөнья чемпионаты 12 октябрьдән алып 16 октябрьгә кадәр Бишкек шәһәрендә үтәчәк.

- Дөнья чемпионатында кырыктан артык илдән көрәшчеләр катнаша, - диде Л.Гайнанова. - Америка белән Австралиядән кала, барлык дөнья кисәкләрендә дә безнең спорт төре үсә, бөтен җирдә дә милли беренчелекләр үткәрелә. Билбау көрәше буенча ярышлар Казанда 2013 елгы Универсиада кысаларында үткәреләчәк. Әлеге факт безне олимпияле итеп тануга бер адым булып торыр, дигән өметтә калабыз.

Сүз уңаеннан. Башкортларда да, татарларда да, чуашларда да көрәш Җыен, Сабантуй һәм Акатуй кебек милли бәйрәмнәрнең мөһим элементы булып тора.

***PROKAZAN.RU***
***Фото wrestlingua.com сайтыннан алынды***



# РФ Дәүләт Думасы регионнарга дини бәйрәмнәрне ял көне итеп игълан итәргә рөхсәт бирәчәк

***Россия Федерациясенең Дәүләт Думасына яңа закон проекты кертелгән. Закон кабул ителгән очракта, төбәкләр, җирле традицияләр белән бәйле рәвештә, өстәмә бәйрәм көннәре кертә алачак. Бу хакта itar-tass.com сайты хәбәр итә.***

Яңалык кертү мөмкинлеге иң әүвәл халыкның күпчелек өлешен мөселманнар тәшкил иткән республикаларга насыйп булыр. Закон проекты авторлары булып гражданлык, җинаять, арбитраж һәм процессуаль закон чыгаручы комитет башлыгы Павел Крашенинников һәм Дәүләт Думасының беренче вице-спикеры Олег Морозов тора.

"Хезмәт кодексы"ның 112 нче маддәсе нигезендә без субъектларның өстәмә бәйрәм көннәре билгеләү хокукын федераль үзәк нигезләмәсе белән ныгытабыз. Алар үз законнары белән нинди бәйрәмнәр булганын үзләре хәл итә", - дип аңлатты әлеге проектны П.Крашенинников. Ул әлеге мөмкинлек алуны исә "хезмәт турында закон чыгару бездә ил һәм аның субъектлары белән бергәлектә эшләүгә нигезләнгән" булуга басым ясады. Павел Владимирович шулай ук намус иреге һәм дини берләшмәләр хакындагы законга да таянуын белдерде.

Закон проекты тәкъдим ителгәнче Башкортстан Республикасында өстәмә дини бәйрәмнәр билгеләргә мөмкинлек бирә торган җирле закон чыгаручы актларны РФ Югары суды законсыз дип тапкан иде. Республика Президенты Рөстәм Хәмитов моңа җавап итеп РФ Югары судына "әлеге карарны гадел түгел һәм ул Башкортстанда яшәүче ике миллионнан артык мөселманнарның хокукларын кыса", дип әйтте. Чынлыкта, Р.Хәмитов мөселманнарның олы бәйрәмнәре булган Ураза һәм Корбан гаетен эш көннәре итмәүне таләп иткән иде.



lenta.ru

*РФ Дәүләт Думасы бинасы.*

# "МЕТЕОР КЕБЕК ЯЛТЫРАДЫ"



***"Гап-гади татар авылында егерме ел эчендә бишенче тапкыр фәнни-гамәли конференция оештырыла. Һәм, беренчесендәге кебек үк, күпме кеше җыелган! Без бу юлы да бертуган Бубыйларның эшчәнлеге никадәр дәрәҗәле, никадәр әһәмиятле булуы хакында сөйләшергә җыелдык".***

"Иж-Бубый мәдрәсәсе - рухи мирас" темасына багышланган фәнни-гамәли конференциядә ясаган чыгышын Казан (Идел буе) федераль университеты доценты, тарих фәннәре кандидаты Альта Мәхмүтова әнә шундый сүзләр белән башлады. Бубыйлар эшчәнлегенең бөтен татар халкы өчен булган әһәмиятен бик тә кызыклы дәлилләр белән раслады ул. Мәсәлән, моннан җиде ел элек Казан дәүләт университеты (хәзерге КФУ), бөтен дөнья галимнәрен җыеп, үзенең 200 еллык юбилеен зурлап билгеләде. Ә XX гасыр башында "Татар университеты", "Мөселман академиясе" исеменә лаек булган Иж-Бубый мәдрәсәсенә моннан 230 ел элек үк, ягъни 1781 елда нигез салынган. Димәк, ул Казан университетыннан чирек гасыр чамасы өлкәнрәк булып чыга. Горурланырга урын бармы? Һичшиксез, бар!

Быел Иж-Бубый авылын мәгариф учагына әверелдереп, бөтен татар-мөселман дөньясына танытькан бертуган Бубыйларның да юбилей елы. Гобәйдулла Бубый дөньяга килүгә 145, Габдулла Бубыйның тууына 140 ел.

Мәгълүм булганча, Бубыйлар эшчәнлеге Совет власте елларында йозак астында тотылганда язучы-галим Мөхәммәт Мәһдиев алар турында "Казан утлары" журналында зур күләмле мәкалә бастырып чыгара. Ул 1896-1911 елларда Иж-Бубый авылы "метеор кебек ялтырап алды" дигән бәяләмәсен биреп, үзенә кыенлык алса да, Нигъмәтуллиннар эшчәнлеген халыкка җиткерә.

Туган авыллары Иж-Бубыйны бөтен Россиядә даншөһрәт казанган, төрки-мөселман дөньясында зур абруйга ия булган белем учагына әверелдерү өчен Нигъмәтуллиннарның бөтен гаиләсе җаннарын-тәннәрен кызганмыйча эшли. Истанбулда төпле дөньяви белем алган Гобәйдулла Габделгаллэм углы Бубыйда мәдрәсәне яңартуның теоретик нигезләрен булдырса, Габдулла Бубый аның гамәли җитәкчесе булган. Ул җәмәгать эшлеклесе һәм ялкынлы публицист буларак та киң таныла.

Филология фәннәре кандидаты Раиф Мәрдановның "Татар мәгърифәтенең күренекле төбәге" дигән чыгышы да конференциядә катнашучыларда зур кызыксыну уяты. XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында Әгерҗе төбәгенең милли мәгариф тарихында зур урын биләгәнен искәрткәннән соң, Раиф Фәтхелбаян улы: "Аны хәзерге Әгерҗе районы чикләре белән генә тәңгәлләштерү дөрес булмас. Бу төбәккә элекке Вятка губернасының Сарапул һәм Алабуга өязләренә кергән бөтен татар авылларын кушып карагадыр. Ягъни хәзерге Әгерҗе, Менделеевск, Алабуга районнарындагы һәм Удмурт Республикасы боларга чиктәш татар авыллары бердәм мәгърифәт атмосферасында яшәгән".

XIX йөз ахырында татар-мөселман мәгариф системасы үзгәреш-яңарыш кичерә. Мәктәп-мәдрәсәләрдә яңача (җәдитчә) укыту тәртипләре урнаша башлый. Гасырлар буена үзгәрешсез килгән кадимчә укыту инде искергән була. Россия мөселманнары арасындагы җәдитчелекнең төп идеологларыннан берсе Исмәгыйль Гаспринский (1851-1914) була.



Бу үрнәктә беренчеләрдән булып, Әгерҗе, Бәйки һәм Бубый мәдрәсәләре үзгәртеп корылган. Иж-Бәйкидәге мәдрәсәнең ул чордагы мөгаллиме Хәялетдин Хәсәнкаев татар мәгърифәтчесе һәм дәреслекләр авторы буларак танылган. Ул 1891 елда Әгерҗедә укыткан вакытында Бакчасарайга барып, Гаспринский белән күрешкәч, җәдитчә укыту ысулларын өйрәнгән. Истанбул белән Мисырга да сәфәр кылып, алардагы уку-укыту тәртипләрен үзләштергән. Иж-Бубый мәдрәсәсе 1895 елдан башлап җәдитчә укытуга күчкән. Татар иҗтимагый фикерендә тирән эз калдырган бертуган Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә Бубый-Нигъмәтуллиннар тырышлыгы белән Иж-Бубый авылындагы мәдрәсә, татар җәдит мәдрәсәләренең берсе буларак, аеруча зур шөһрәт казанган.

Фәнни-гамәли конференциядә чыгыш ясаган тарих фәннәре кандидаты Рафилә Гыймазова, филология фәннәре кандидаты Гөлфия Гайнуллиналарны да залда утыручылар зур игътибар белән тыңлады. Аларның беренчесе "Татар иҗтимагый фикер үсешенә Габдулла Бубый һәм Якуб Хәлимнең керткән өлеше", икенчесе "Тарихлардан килгән хакыйкать" темаларына тукталды.

***Харис ЗАКИРОВ,***
***1957-1960 еллардагы Иж-Бубый мәктәбе шәкерте***

# ИСТӘЛЕКЛӘРДӘН АЛЫП ФАРАЗЛАУЛАРГА КАДӘР

## 12 октябрьдә Казанда II Саматов укулары үтте.

***ТР мөселманнары Дания нәзарәте оештырган II Саматов укуларына Россиянең күп кенә төбәкләреннән дә мөфтиләр һәм дин әһелләре килде.***



Чара Коръән сүрәләре уку белән башланып китте.

Вәлиулла хәзрәт Якупов узган ел Габделхак Саматовның тууына 80 ел тулу билгеләп үтелгәнлеген искәртте.

ТР мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз кунакларга рәхмәт сүзләрен җиткердė, Габделхак Саматовның Аллаһ тарафыннан җибәрелгән юл яктыртучы булуын әйтте.

Габделхак хәзрәтнең улы Таһир хәзрәт Саматов әтисе турындагы истәлекләр белән уртаклашты. Аның һәрвакыт гыйлем, нәсихәт бирүен, ихлас күңелле булуын ассызыклап узды.

Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин әлеге чараны РИУның зур конференц-залында үткәрергә, шәкертләрне дә бу эшкә кертеп җибәрергә кирәк дигән тәкъдим ясады.

Үзәк Диния нәзарәтенә караган Мәскәү мөфтияте җитәкчесе, Чуашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Кргванов та Г.Саматовның укучысы булган икән.

Самара өлкәсе мөфтие Вәгыйзь хәзрәт Яруллин - Саматов исемендәге премиянең беренче лауреаты иде. Быелгы "Рухи мирас" премиясен ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус Фәиз түбәндәге сүзләр белән тапшырды:

"Иң беренче киңәшчем, остазым, хикмәтле сүзләре белән Габделхак хәзрәтләрнең юлын дәвам итүче, безгә юл күрсәтүче, Саматов укулары идеясен кертүче кеше - Җәлил хәзрәт Фазлыев - ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең баш казыена II "Рухи мирас" премиясен тапшырабыз".

Җәлил хәзрәт исә бераз югалып калды. Бу бүләкнең көтелмәгән булуын әйтте, үзенең лаек булуына шиген белдерде:

- Аллаһы Тәгалә алдагы гомерне шушы бүләккә лаек булырлык итеп үткәрергә насыйп итсә иде. Ул бик зур бурыч та йөкли, - диде ул.

Конференциянең фәнни өлешендә исә сүз дин әһелләре, милли үзенчәлекләр, Әбү Хәнифә мирасы, Габделхак хәзрәтнең ислам дине үсешенә керткән роле турында барды.

Гомәр Саматов абыйсы турындагы хатирәләре белән уртаклашты.

Россия стратегик тикшеренүләр институтының Идел буе төбәге һәм дини эзләнүләр үзәге җитәкчесе Рәис Сөләйманов та чыгыш ясады. Ул оешкан җинаятьчел төркемнәр һәм сәләфиләр турында, Татарстанда дини фундаментализм һәм җинаятьчелек кушылуы хакында сүз алып барды.

II Саматов укулары Габделхак хәзрәт турындагы истәлекләр белән уртаклашу, аның рухына багышлап дога уку белән тәмамланды.

**Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА**

# ДИН ҺӘМ МИЛЛӘТ – КЕШЕНЕҢ ИКЕ КАНАТЫ УЛ

**Чынлыкта, милләтчелек феноменын аңлау өчен тирән сәбәпләр эзләргә дә, тарих төпкелләрендә дә казынырга кирәкми. Әлеге феномен турында күпләгән китаплар һәм хезмәтләр язылган.**

Кыскасы, милләтчелекнең барлыкка килүе аерылгысыз рәвештә милли дәүләтләр барлыкка килү белән бәйләнгән. Бер генә сорау туа - кайсысы иртәрәк "пәйда булган": йомыркамы яисә тавыкмы, ягъни милләтчелекме, әллә дәүләтме? Кемдер "башта милләтчелек барлыкка килгән һәм ул милли дәүләтләрнең барлыкка килүенә китергән", дип саный. Икенчеләре исә, милләт-дәүләт формалашканнан соң, милли идеология дә формалаша башлаган, ди. Минем уйлавымча, һәрхәлдә, тарихта беренче вариант та, икенчесе дә булган. Безнең мисалда исә шунысы мөһим: милләтчелекне Европа уйлап тапкан һәм аның барлыкка килүе дә аерылгысыз рәвештә дини институтлар кризисы белән бәйләнгән. Халыклар (үзләрен нығыту, саклап калу өчен) күп очракта милләтне дингә каршы куярга яки милли мәнфәгатьләргә күбрәк өстенлек бирергә теләгән. Әлбәттә, милләтләр формалашу мәсьәләсе күпкә катлаулы һәм күптөрле.

Безнең аңыбызга кереп утырган "милләт" төшенчәсе европалылар тарафыннан тудырылган. Аңа XVII-XVIII гасырларда нигез салына, ә үзенең җитди үсешен ул XIX йөздә туплый һәм XX гасырда дәвам иттерә.

Европада милли дәүләтләр дини җәмгыять һәм династияле-империяле дәүләт кебек мәдәни системалар кризисыннан соң барлыкка килә. Ул диннәрнең "изге телләр" (латин (латынь), гарәп һ.б.) һәм "монарх хакимияте илаһтан", дигән күзаллауларның кризисы белән бәйле була. Әгәр дә башта Европада күпчелек танылган галимнәр үзләренең хезмәтләрен латин телендә язган булса, тора-бара алар әлеге тәҗрибәне кире кагып, үзләренең хезмәтләрен гади халык телендә яза башлаучы галимнәр төркеменә кушыла һәм шуның нәтиҗәсендә, халык теле милли тел булып китәр иде. Хәтта халкыбыз тарихында да, без моны XIX гасыр татар мәгърифәтчеләренең тора-бара гарәп теленнән татар теленә күчүләре мисалында күрә алабыз.

Милли дәүләтләр барлыкка килгәнче җәмгыятьнең төп идеологик нигезе булып дин торган. Күпчелек очракта үзләрен дингә каршы кую аша яңа милли дәүләтләр төзелгән: дин урынына яңа милли идеология килергә, дин икенче планга күчәргә тиеш була. Бу - радикаль рәвештә үзенең мәдәнияте, идеологиясе, иконостасы белән яңа совет халкын "ясаган" Советлар союзында да булды.

Милләтләр формалашуда мөһим фактор булып, яңа текстлар һәм символлар корпусын тудыру, дини кыйммәтләр системасын алыштырга лаеклы югары милли мәдәният оешу тора. Россиянең күп кенә мәдәни- лингвистик төркемнәрендә югары культура оешу 1917 елга кадәр үк башкарыла һәм бу совет елларында тулысынча тормышка ашырыла да. Безнең мисалда "югары культура" төшенчәсе астында махсус укытылган белгечләр, милли элита - рәссамнар, язучылар, драматурглар, галимнәр тарафыннан булдырылган һәм барлык берләшмә әгъзалары тарафыннан кабул ителгән мәдәниятне аңларга кирәк. Шунысын да искәртеп үтик: "югары культура" дигәндә, дингә һәм халык мәдәниятенә каршы куелган язма мәдәният күздә тотыла.

Тарихта мондый мисаллар шактый. Мәсәлән, "яңа" Төркия дәүләтен төзегән Мостафа Кемаль (Ататөрек) динне милләт мәнфәгатьләренә буйсындыра. Аның дингә мөнәсәбәте шактый каты булган милли дәүләт моделе Европадан, төгәлрәк әйткәндә, Франциядән алынган була.

Гомумән, Франция эзлекле рәвештә динне дәүләттән аеручы секуляристик идеологияле ил булып тора. Әлеге процессның башлангычы - 1789 елдагы Бөек Француз революциясе. Француз революционерлары иҗтимагый-сәяси системаны тамырдан үзгәрткәннән соң, Париждагы Изге Ана соборын Аң храмы (Храм Разума) (XIX гасырда Наполеон аңа элеккеге исемен кайтарган) дип йөртә башлый. Француз революциясе нигезендә туган дөньяви гуманизм идеясе дингә үзенчәлекле альтернатива була.

Әлеге карашларның нәтиҗәсен без хәзер дә, Азәрбайҗан кебек Урта Азиянең яшь дәүләтләрендәге яңа элитаның дин белән көрәш алып баруында яисә дингә икенчел дәрәҗәдәге, символик урын бирергә тырышуларында күрәбез. Әлеге процесслар Мисыр яки Тунис кебек яңа гарәп дәүләтләрендә дә күзәтелә.

Кызганыч, әлеге тенденцияләр безнең тарихыбызны да читләтеп үтми. Татар милләте өчен җан атып йөрүчеләр арасында да, күпчелегенең исламга карата мөнәсәбәтләре я тискәре, я кимсетүле. Бу бигрәк тә нигезендә нәкъ менә тел милләтчелеге булган совет чорындагы татар зыялылары мисалында ачык күренә. Алар динне никах туенда яисә кеше җирләгәндә генә искә алган.

Совет чорыннан соң, татар милләтенә күбрәк "туры килгән" үзенчәлекле милли төрки/татар диненә - тәңречелеккә карата мода барлыкка килде. Моңа охшаш ситуацияне без Мәскәүдәге тарихи Җәмигъ мәчетен "үзгәртеп кору"да да күзәттек: әлеге бина кемнәрдер өчен Россия башкаласында халкыбызның яшәү символы булган булса, башка милләтләр өчен ул гыйбадәт кылу урыны иде.

Тарихта булган диннән баш тартулар, чор белән бәйле мәнфәгатьләргә буйсыну - халкыбызны хәзерге кризиска алып килүгә ачык мисал. 1917 елдан соң татар милләтен диннән башка гына "төзеделәр". Нәтиҗәдә, динне генә түгел, телебезне дә югалтып, милли бөтенлегебез какшау, ассимиляцияләнү куркынычы яный башлады.

***Илһам ВӘЛИЕВ***
***info-islam.ru сайтыннан***
***Гүзәл Шәмсиева тәрҗемәсе***



(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

# Сөембикәнең серләре күп

**- Сафагәрәй - Сөембикәнең икенче ире. Ул нинди хан булган?**

- Узган елны Сафагәрәйнең туына 500 ел булды. Ул 1510 елда дөньяга килгән. Сафагәрәй 14 яшендә Казан ханлыгының башында торып, халыкның мәхәббәтен яулый. Мәскәү гаскәрләреннән азат итеп, үзенә кешеләрнең ышанычын уята. Ул бик көчле ихтыярлы, талантлы шәхес була. Мәскәүгә буйсынмаган. 1536 елдагы сугышта ул Җангали тарафыннан Мәскәүгә бирелгән Нократ, Ока елгасы җирләрен кире кайтаруга ирешә. Шушы вакыйгалардан бик тәэсирләнеп, Сафагәрәй Польша короле Сигизмунд Беренчегә хат яза. "Берләшергә кирәк, Мәскәү һәркемгә куркыныч, бер-беребезгә терәк булыйк", дип язылган хатны галимә Динә Мостафина тапты. (Мустафина Д.А. Послание царя Казанского. Письмо хана Сафа-Гирея польскому королю Сигизмунду I / Д.А.Мустафина // Гасырлар авазы - Эхо веков. - 1997. - №1/2. - С.26-38.) Ул тарихи әсәр шикелле укыла. Бу Сафагәрәйнең оста дипломат булуын дәлилли. Аның шигырьләре барлыгы да билгеле. Казан ханы фарсы телен камил белгән. Сафагәрәй исән чакта Казанны алып булмаячагын Мәскәү дә, Казан дошманнары да яхшы аңлый. Ул 1549 елның мартында 39 яшендә үлә. Юынган чакта, имеш, егылган һәм ташка бәрелгән. Ләкин чынында аңа астыртын һөҗүм иткәннәр. Сафагәрәй таза, ярау (олы) гәүдәле сугышчы була, аның мондый кинәт үлеме шик тудыра.

Казан халкы кайгыга кала, тәхеткә утыртыр өчен Сәхипгәрәйне сорап Кырым ханлыгына мөрәҗәгать итәләр, ләкин госманлы империясеннән ярдәм булмый. Нәтиҗәдә, идарә өч-дүрт яшьлек Үтәмешгәрәйгә кала. Ләкин, чынлыкта идарә эшләрен Сөембикә алып барган. Аңа атаклы гаскәр башлыгы Кузыйчак угълан ярдәм иткән, киңәшләр биргән, ул да чыгышы белән Кырым ханлыгыннан була. Ханлыкта Сөембикә турында төрле имеш-мимеш тарала, алар Кузыйчак белән сөяркә дигән сүзләр йөри башлый, киеренке хәлләрдә бердәмлек югала, котыртулар нәтиҗәсендә Казанда Мәскәү партиясе җанлана. 1550 елда Мәскәү һөҗүм ясый һәм җиңә, ханлыкның тау ягын дошманнарга бирәләр. Руслар килеп Зөя каласын кора башлый. Алар гаскәр туплау өчен әзерлек эшләрен җәелдерәләр, утрауга кораллар, азык-төлек китереп тутыралар. Максат - Казанны яулап алу. Казанга ультиматум куя башлыйлар. Ханлыкның бер өлеше, бирелергә, Мәскәү белән кушылырга тиеш була. Руслар: "Сугыш булмасын өчен Сөембикәне бирегез", - диләр. 1551 елның 11 августында Сөембикә мәңгегә Казан белән хушлаша. Аны башта Зөягә алып китәләр, аннары Мәскәүгә озаталар.

**- Ә Сөембикәне улы белән руска тоттырып җибәрмәсәләр, Казан яуланмас идеме? Ханбикәнең Мәскәүгә озатып җибәрүдә Кол Шәрифнең дә кулы уйнаган дигән сүзләр йөри, моны исбатлаган мәгълүмат бармы?**

- Татарларга оборонаны әзерләү өчен вакыт кирәк бит. Казанлылар Сөембикә һәм аның улын, гаиләсе белән Кузыйчакны биреп җибәрергә мәҗбүр була. Вакыт сузылмасмы, дип өметләнгәннәр, вакытлы компромисска барырга туры килә. Казан сугышка әзер булмаган, дәүләт "ә" дигәнче тар-мар ителер, каршы торырга өлгермәс иде. Шаһгали да Казанның җитмеш бәген алдап дигәндәй кунакка чакыра һәм руслардан үтерттерә. Аларның күбесе Казанның оборонасы белән идарә иткән була. Димәк, Казанның идарәсендә талантлы шәхесләр калмый диярлек. Кол Шәрифкә килгәндә, ул үзе генә берни дә хәл итә алмаган. Аның Казанны сатарга мөмкинлеге булган, чөнки барлык хатлар аңа килә, руслар ягына чыга алыр, үзе дә әсирлеккә төшәр иде. Кол Шәриф - иманлы кеше, ул Казанның патриоты. Нишләтәсең, тәкъдиребез шулай язылган булгандыр. Наполеон да Мәскәүгә кергәч, Кутузов: "Мәскәү әле ул Россиянең һәлак булуы түгел", - дип әйтә. Татарлар да шулай уйлап эш иткәннәр, күрәсең.

1552 елгы вәзгыять киеренке хәлдә була, оборона белән Кол Шәриф тә җитәкчелек итә. Җәен Казанга ирекле рәвештә Мәскәү воеводасы килеп утырырга тиеш булган. Аны ханлыкка өч татар бәге озата килә, ләкин алдан чабып китеп, капкаларны эчтән ябып куялар. Алар: "Руслар безне барыбер суячак, сугышып үлик!" - дип, халыкны көрәшкә күтәрә. Августның егермеләрендә гаскәр килеп, Казанны чолгап ала. Ханлык оборонага әзер, аның ризык запасы ике-өч елга җитәрлек була.

Мәскәүнең Казанны алуында Европа руханиларының да мәкере зурдан була. Алар Явыз Иванны мөселман татарларын юк итәргә кирәк, дип котырта. Бу - тәре походының бер чагылышы. Казанны алганда Германия, Англия инженерлары русларга заман технологияләре белән шәһәрләрне җимерү ысулларын өйрәтә. Англия галиме Бутлер җитәкчелегендә тоннель казып, Кремль диварлары астына дары тутыралар һәм саклау ныгытмаларын шартлаталар. Шактый кеше һәлак була, ләкин тоннельдән керүче дошманнарны уздырмыйлар. Һөҗүмгә каршы тора алдык, дип сөенү була, икенче, өченче җирдә янә шартлаталар, татарлар рухи төшенкелеккә бирелә, бу рәвешле шәһәрләрне әле алмаган булалар. Шәһәрне саклау бик авыр бара. Тагын 15-20 көн дәвам итсә, руслар ачка киселеп, туңып кире китәр, җәй көне чабата белән килүчеләр озакка түзмәс иде. Сатлык Камай мирзаның хыянәте безне харап итә, эчә торган чишмәне шартлаталар, казанлылар сусыз кала.

**- Кремльдә экскурсия уздырганда Сөембикә манарасына килеп җиткәч, гадәттә, кешеләргә Сөембикәнең 7 көн эчендә Явыз Иваннан манара төзеттереп, соңгы көнендә халкы, Казан белән хушлашыр өчен иң югарыга менеп, манарадан сикерү риваятен сөйлиләр. Чынлыкта, Сөембикәнең язмышы канлы күз яшьләре белән искә алына торган фаҗига. Аның һәм Үтәмешгәрәйнең тормышы ни белән тәмамлана?**

- Сөембикәне Мәскәүгә алып киткәч, әтисе Йосыф мирза Явыз Иванга: "Зинһар, кызым белән улымны бир", - дип, үгетләп хат яза. Мәскәү башлыгы аңа: "Кызың яхшы шартларда яши, аны Шаһгалигә кияүгә бирдек, ул үзен бәхетле тоя", - дип җавап бирә. Йосыф мирзага, Сөембикәнең "борынын, колакларын кисканнәр", дип хәбәр итәләр. Иван Васильевич (Грозный) мәрхәмәтлелек күрсәтми. Мәскәү патшасы котыртуы нәтиҗәсендә Нугай Урда халкы үзара сугыша. 1555 елда Йосыф мирза һәм Мәскәүгә сатылган бертуган энесе Исмәгыйль мирза гаскәрләре арасында канлы бәрелеш була. Йосыф мирза үтерелә. Сөембикә яклаучысыз кала, аны кайгыртучы булмый. Ул 1556-1557 елларда вафат була. Ханбикәнең кабер ташы сакланмаган. Шаһгали Сөембикәне яратмаган: ул аны берничә тапкыр агуларга да маташкан. Үтәмешгәрәйне дүрт яшендә әнисеннән аералар һәм көчләп чукындыралар. Ул Мәскәү Кремлендәге монастырьдә үлә. Татар баласы "Александр Сафагиреевич" исеме белән җирләнгән. Аның кабере Симеон Касаевич исеме белән җирләнгән Ядегәр хан янәшәсендә (Үтәмешгәрәй янына Иван Дүртенче дә күмелгән).

Касыйм татарлары риваятьләре буенча, Касыйм шәһәрендәге ханнар төрбәсендә Сөембикә дә җирләнгән. Анда бик күп кабер ташларын ватып бетергәннәр, нинди таш тапканнар, барысын да шунда китереп тутырганнар. Ханнар төрбәсе икән, анда каберләр дә санаулы булырга тиеш. Берсе - Шаһгалинең атасы Данияр, башкалары - хатыннарының каберләре булырга мөмкин. Шаһгалиның балалары юк. Бер кабер ташында Бүләк Шатбикәм дип язылган. Татар галимнәре биредә Сөембикә җирләнгән, дип фаразлый. Ташта 37 яшендә вафат булган, диелгән. Бүтән мәгълүмат юк. 1520 нче елларда туып, 1556 нчы елларда үлгән булса, ул Сөембикәгә туры килә.

Бер чыганакта да Сөембикә шушы җирдә туган, дип әйтелми. Ләкин, Мамадыш районының Арташ авылында ханбикәне "безнең авыл кызы", дип әйтәләр. Аның турында төрле имеш-мимешләр дә сөйлиләр, имләүләр тексты да сакланган. Нугай Урдасы кабиләләренең Нократ елгасы тирәсенә килеп утыруы бик тә мөмкин. Аларның бу тирәгә килеп төпләнүләре XV гасырның икенче яртысында башлана.

Сөембикә манарасы турында да кызыклы фактлар бар. Рус архитекторлары һәм безнең Нияз Халиков, манара "1711-1720 нче елларда салынган", дип яза. Беренчедән, моны исбатлаучы бер генә документ та юк. Икенчедән, ул вакытта татарны басып алган руска нәрсәгә кирәк булды икән шундый зур корылма төзеп яту? Ул күпләгән чыгым һәм көч таләп итә. Казанда салынган барлык манараларның да документы бар, ә Сөембикәнеке юк. 1240 еллар тирәсендә француз короленең вәкилләре Алтай якларына сәяхәт кылганда "татарлар үлгәннәрнең каберенә манаралар салдыра", дип язып калдырган, рәсемнәр ясаган. Корылмада Алтын Урда архитектурасы традицияләре нык чагыла. Сөембикәнең: "Хан каберенә кордырдым манара", дигән язуы да билгеле. Бу - Сафагәрәй каберенә корылган манара, дип фаразлана. Ул төзелгәндә шымчылар, татарлар сугышка әзерләнә дип, Мәскәүгә донос яза. Сөембикә манарасы, бигрәк тә аның төбе, нигезе бүгенгәчә өйрәнелмәгән. Анда ике ишек бар, берсен ачсаң, манарага менәргә мөмкин. Ә икенчесе кая таба бара? Манарага исемне руслар кушкан, дип уйлыйм, татарлар аны "хан мәчете манарасы", дип йөрткән.

Сөембикәгә кагылышлы ачыкланмаган серләр шактый әле.

***Римма БИКМӨХӘММӘТОВА,***
***"Ирек мәйданы" газетасыннан алынды***

# ХИКМӘТЛЕ ТӨШ



***Җир җимертеп эшләп йөргән җиреннән үзен начар хис итә башлады Вәли. Ул, хәлсез аякларын сөйрәп, караваты янына барды да йомшак мендәргә башын куйды. Тәне буйлап узган илаһи бер көч аның буыннарын йомшартты һәм күзләрен йомарга мәҗбүр итте.***

Вәлинең сулышы тигез, йокысы тирән иде. Ләкин бу тирәнлекнең ниндидер бер сихри көчкә буйсынганы сизелеп тора. Йоклаганда мондый тойгылар кичергәне юк иде әле аның. Тик нәрсә соң бу? Шайтан шаярамы, әллә бу бер куркыныч төшме?

Көтмәгәндә бер шәүлә пәйда булды. Аның тавышы Вәлине сискәндереп җибәрде. Ул илаһи затның чалымнарын гына күрсә дә, аның бик якын икәнен сизә иде. "Бер-бер хәл булганчы, тизрәк качарга, качарга кирәк моннан", - дип уйлап та өлгермәде, шәүлә берничә тапкыр "ух-ух" итте дә, телгә килде.

- Азапланма, адәм баласы. Син - Аллаһы Тәгаләнең бер улыколыдыр, сиңа аның тәкъдиренә буйсынып яшәүдән башка чара юк. Шул очракта гына ил имин, тыныч булыр. Сиңа безне җиңәрлек көч бирелмәгән.

- Кем син?! Минем нинди гөнаһларым, ни гаебем бар соң?

- Курыкма, без сиңа зыян салмабыз. Син - татар баласы, хак дин юлындагы кешедер. Сиңа зур бер хакыйкатьне ачарга телибез. Игътибарлы бул!

Шәүлә юкка чыкты. Мизгел эчендә күз аллары яктырып алды. Ләкин бу яктылык күзләрне чагылдырмый, ә киресенчә, ниндидер тылсымлы бер көчкә ия булгангамы, тынычландыра һәм үзенә тартып тора иде.

Вәли игътибар белән тирәягын күзәтергә тотынды. Көтмәгәндә, Вәлине гаҗәпләндереп, бер күренеш пәйда булды.

Таш дала. Уртасында гаҗәеп сылу бер алмагач үсеп утыра. Юан, алтынга манылган кәүсәдән озын, туктаусыз хәрәкәт итүче ботаклар сузылган. Чү, ботаклар түгел, аларда үскән алмалар салмак кына тибрәлә икән ләбаса. Алар, әле хәрәкәтләнеп кенә калмыйлар, үзара пышылдашып, бер гүләү хасил итәләр. Алмаларны искиткеч гүзәл, күз явын алырлык нурлар сибеп, ялт-йолт итеп тора торган яфраклар уратып алган.

Вәлине сискәндереп, алмагачтагы бер алма өзелеп төште дә нидер жырлый-жырлый дала буйлап тәгәрәде. Тик көтмәгәндә җыр өзелде һәм алманың ачы итеп кычкырган тавышы ишетелде. Вәли шул якка карады һәм еракта упкын бар икәнен абайлап алды. Анда туктаусыз ут янып тора иде.

- Я, аңладыңмы инде, адәм баласы?

- Нәрсәне?

- Бу алмагач сиңа бер нәрсә турында да сөйләмиме?

- Юк.

- Алайса, тыңла. Алмагач - ул бербөтен, ул - татар милләте. Татар халкының бөтен матурлыгы, тарихы, моңы, җыры - кыскасы, һәммәсе шушы агачта. Үзең кара: кайрысы нинди затлы, димәк, татар халкы да затлы, үз дигәненә ирешүче, гадел, тырыш. Ә яфраклары - тел. Алар шундый матур бизәкле, әйтерсең лә татар теленең байлыгын чагылдыра.

- Ә алмалары?

- Алмалары - синең кебек үк адәм балалары. Алар бик еш татарлыкларыннан читләшәләр, башка телгә, дингә табыналар, шул рәвешле көчле милләтне җимерәләр. Үзең күрдең: бер алма өзелде дә һәлак булды, аның артыннан күпме яфрак, ботак коелып калды.

- Шулай шул.

- Адәм баласы, мин беләм: син милләтеңне яратасың, аның өчен җан атып яшисең. Татар дигән бөек исемне саклап каласың килсә, күргәннәреңне халыкка сөйлә. Аңлат аларга милләт сүзенең бөеклеген, милләтнең көчен. Борчылма, син булдырырсың, без сиңа һәрвакыт ярдәм итеп торырбыз. Сау бул, дустым!


Вәлинең күңелендә бик күп сораулар туган иде, ул аларны бирергә өлгермәде, уянып китте. Уянды да салкын тир бәреп чыканын тойды. Бераз түшәмгә карап ятты да:

- Әйе... - диеп куйды.

Бу сүзгә нинди мәгънә салынган булгандыр, анысы Вәлинең үзенә генә мәгълүм иде.

**Алмаз МАНСУРОВ,**
**КФУның IV курс студенты**

# ТӘКЪВАЛЫК



***Тәкъвалы булу ул - Аллаһка буйсыну һәм аңа итәгать итмәүдән баш тарту; Аны истә тоту һәм онытмау; Аңа рәхмәт әйтү һәм яхшылыкны белүче дигән сүз. Бу кагыйдәне яшерен рәвештә дә, ачык рәвештә дә, төрле хәлләрдә дә тотканнар.***

Мин әлеге язмамда авылыбызның иң тәкъва кешесе - Мәдинә апа белән таныштырырга телим. Ул - үз чоры хатын-кызлары кебек үк, тормышның барлык авырлыкларын татый, башкалар кебек сөя дә, сөелә дә белә. Үз тиңен табып ике ул үстерә, әмма ире хыянәт итә. Балалар атасыз үсә. Кече улы кинәт кенә авырып, вафат була. Олы улы Миңнәхмәт хәрби кеше була. Лаеклы ялга чыккач, ялгыз әнисен тәрбияләү өчен, шәһәр уңайлыкларыннан баш тартып авылга кайтып яши. Әй, авыр да бирелә инде тормыш кайберәүләргә. Түз генә! Соңгы өмете - олы улы да илле өченче яшендә йөрәк авыруыннан дөнья куя. Бик авыр ялгыз анага. Авыр минутларында авыз эченнән көйләп:

**Тәрәз төбем исле гөл,**
**Санадым сигез түгел.**
**Язмышыма үпкәләмим,**
**Бармак та тигез түгел, -**
**дип, үз-үзен юата ул.**

Мәдинә әбинең ачу саклый белмәвенә, аның тәкъвалыгына бер вакыйга ишарә ясый. Улларының әтисе булган кеше нык авырый башлагач, аның янына бәхилләшергә килә һәм бәхиллеген алып кала. Бу халәтне теләсә кем кичерә алмый, бары тик Аллаһка ышану, Аннан курку гына көч бирә ала моңа. Ирсез килеш малтуарлар асрап, үзенең якын һәм ерак туганнарына атап егермегә якын корбан чала ул. Ә бит үз гомерендә корбан чалып та, ни әрвахларны, ни исәннәрне сөендерә алмаган байлар күпме?

Мәдинә әби, инде көч-хәл белән йөрсә дә, 84 яшендә туганнары ярдәмендә хаҗ гамәлен үтәп кайтты. Минем әлеге язмамны укучылар: "Бу әби бик байдыр инде", дип уйларга мөмкин. Юк, ул матди яктан гына түгел, рухи яктан да искиткеч бай. Мәдинә апа ислам дине кануннарына бик тә тугрылыклы булып яши. Ул ялтыравыклы купшы киемнәр яратмый, чөнки артык күп киемнәребез өчен Кыямәт көнендә җавап тотачакбыз. Минем дустым бары тик мөселман булуның төп биш шартын төгәл үтәүчеләрнең берсе генә: ул - шәһадәт кәлимәсенең асылын аңлап, аны үтәп яши; биш вакыт намаз укый; фарыз уразаларын тота, зәкятен, гошерен бирә. Аллаһы Тәгалә аңа күп нәрсәләрне алдан искәртә: "Улым вафат булгач, өстенә ак җәймә капладык, әйләнеп керсәм, ак җәйменең уртасы ямь-яшел, карап торам, шунда ук юкка чыкты ул төс. Намазга баскач та сәҗдә кыласы урынымда яшел түгәрәк барлыкка килгәли", - ди. Дөнья серле! Яшел төс - чын мөселманлык төсе.


Ул үзе пешергән ризыкларга өстенлек бирә, аның чын тәкъвалыгын да сөйләменнән күрәсең. Мәдинә абыстай чын дөресен генә сөйли, кайберәүләр кебек янында зурлап, артыннан хурлап йөрмәс. "Тормышымда искә алып сөйләрдәй кояшлы көннәрем аз булса да, Аллаһы Тәгаләгә бик рәхмәтлемен: уң ягымда - динем ислам, сул ягымда - нурым бар, сөбханалла, гафуррәхим, синнән якын кемем бар?!" - дип тәмамлады ул үз сүзен.

***Рәшидә ӘҮҺАДИЕВА,***
***Мамадыш районындагы Урта Кирмән мәхәлләсе абыстае***

*Фотода хаҗия Мәдинә НИЗАМОВА.*
*Фото гаилә архивыннан алынды.*

## Китап – иң яхшы бүләк!

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге республикабызның мәчет һәм мәдрәсәләре каршында китапханәләр оештыру максаты белән китаплар җыя.***



Һәркемнең дә шәхси китапханәсендә берничә кат укылган яисә, гомумән, файдаланылмыйча яткан китаплары бардыр. Әлеге китапларны мәчет һәм мәдрәсәләргә бирсәк, алардан башка дин кардәшләребез дә, шулай ук яңа гына динебезгә якынайганнар да файдалы белемнәр ала алыр иде.

Игелекле чарада катнашырга теләге булганнарны Казан шәһәре, Лобаческий урамы, 3 нче кат, 7 нче бүлмәдә көтеп калабыз. Китапларны җыю агымдагы елның 16 ноябренә кадәр дәвам итәчәк.

Барлык сораулар белән дә +7 (843) 236-52-12 яки 89872639889 телефон номерлары аша бүлек җитәкчесе Гөлнара Садыйковага мөрәҗәгать итә аласыз. Электрон почта адресы: sadykova-g@mail.ru.

***DUMRT.RU***

**Белдеру**

***20 ОКТЯБРЬДӘН "МӨХӘММӘДИЯ" мәдрәсәсендә "И туган тел, и матур тел!" дип исемләнгән курслар башланачак.***

Шәкертләргә "Коръән", "Татар теле һәм татар халкы тарихы", "Ислам дине нигезләре" фәннәрен укыту каралган.

Бирегә теләгән һәркем йөри ала. Дәресләр түләүсез.

**Курсларның дәвамлылыгы - өч ай.**

Укулар **сишәмбе** һәм **пәнҗешәмбе** көннәрендә ***18.00 сәгатькә*** билгеләнгән.

Белешмәләр өчен телефон: 8-927-415-85-99 (***14.00 сәгатьтән 23.00 сәгатькә кадәр шалтыратырга мөмкин***).

**Белдеру**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 15.10.2011 | 05:45 | 07:13 | 13:02 | 15:48 | 17:44 | 19:11 |
| *Якшәмбе* | 16.10.2011 | 05:47 | 07:15 | 13:02 | 15:45 | 17:42 | 19:09 |
| *Дүшәмбе* | 17.10.2011 | 05:49 | 07:17 | 13:02 | 15:43 | 17:39 | 19:06 |
| *Сишәмбе* | 18.10.2011 | 05:51 | 07:19 | 13:02 | 15:41 | 17:37 | 19:04 |
| *Чәршәмбе* | 19.10.2011 | 05:53 | 07:21 | 13:02 | 15:39 | 17:34 | 19:02 |
| *Пәнҗешәмбе* | 20.10.2011 | 05:55 | 07:23 | 13:02 | 15:37 | 17:32 | 19:00 |
| *Җомга* | 21.10.2011 | 05:57 | 07:25 | 13:02 | 15:34 | 17:30 | 18:57 |

***Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды***


# ЙОКЛАП КАЛМА!



Рус телендә нәшер ителүче **"УММА" ГАЗЕТАСЫНА 2012 елның I яртыеллыгына** язылу башланды. Моңа кадәр газета республикабызда подпискасыз таратыла иде. Хәзер әлеге басмага Татарстанның теләсә-кайсы почта бүлегендә язылып булачак. ***Газетаның индексы - 83072.***

***Газетага язылу бәясе - 118 сум 38 тиен. Исегезгә төшерәбез: "УММА" - ислам динен яктыртучы атналык газета.***

УММА
НАУЧНО-ПОПУЛЯРНАЯ ГАЗЕТА http://www.e-umma.ru
Умма - это объединение людей в поисках духовности


**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №9 (106) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-509

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 13 октябрь, 17.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**